СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

23 сентябрь, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 108 (8265) | Бәясе билгеләнгәнчә

## СЕССИЯ БУЛДЫ

**1998нче елның 22 сентябрендә хакимиятнең конференц - залында халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советының чираттагы унҗиденче сессиясе булды.**

***Ул хакта тәфсилләп газетабызның киләсе санында язылачак.***

## РӨСТӘМ САБИРОВ:

# «ҮСЕШ КҮЗ АЛДЫНДА»



***Инде хәбәр ителгәнчә, узган атнада Нурлатта "Татнефтепродукт" АҖ предприятиеләре җитәкчеләренең республика семинар - киңәшмәсе булды. Ул хакта язманы газетабызның 2нче битеннән укый аласыз. Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ бу рәсемне семинар - киңәшмәне ачкан чакта төшереп алган. Анда катнашучыларга район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН мөрәҗәгать итә.***

## Район үзәк хастаханәсе:

### ремонт, тагын ремонт!

Финанс кыенлыкларына карамастан, район үзәк хастаханәсе коллективы үзенең биналарын тиешле тәртиптә тоту белән бәйле күп кенә проблемаларны хәл итеп килә. Ул моңа җирле сәламәтлек саклау мәсьәләләренә җитәкчелек итүгә хуҗаларча мөнәсәбәт аркасында ирешә. Ремонт эшләрен оештыру, аерым төр материаллар сатып алуда һәм башка эшләрдә аеруча кулай вариантларны кулланалар. Мәсәлән, буяуны Мари Республикасында - җитештерүче заводның үзеннән һәм күпкә арзанракка алганнар. Моннан тыш, үзәк район хастаханәсендә баш табиб боерыгы белән даими нигездә биш кешедән торган буяучы - сылаучылар бригадасы булдырылган. Аларның барысы да - гамәли стажга ия булган һәм төзелеш оешмаларында эшләгән кешеләр. Быел стационарның кабул итү бүлегендә ("СМУ - 53"), бала тудыру йортында, аш - су хәзерләү блогында, балалар сөт кухнясында һәм стерильләштерү бүлегендә ремонт эшләре башкарылды. Монда линолеумны алыштырырга, түшәмнәрне агартырга, диварларны һәм тәрәзә төпләрен буярга кирәк булды, хәзер хастаханә палаталарында һәм ярдәмче биналарда ямь артты, алар яктырып киттеләр. Киләчәктә неврология, хирургия бүлекләрендә ремонт ясау күздә тотыла.

***

Зуррак башлангычларны да билгеләп үтәргә мөмкин. Мәсәлән, яшелчә саклау урынын төзү дәвам итә. Киләчәктә монда бәрәңге, башлы суган, кәбестә, кишер һәм чөгендерне көздән алып яңа уңышка кадәр сакларга мөмкин булачак. Элек яшелчәләрне саклау урыны булмаганлыктан, барысын да сезон арасында югары бәя белән сатып алырга туры килә иде. Төзелешнең мәшәкате дә, чыгымнары да күп, әмма ул үзен, һичшиксез, аклаячак. Яшелчә саклау урынын бу көздә файдалануга тапшыру күздә тотыла. Кирпеч өю эшләрен 1нче ПМК ташчылары башкара.

***

Финанс хәлләре, барлык башка тармаклардагы кебек үк, сәламәтлек саклау өлкәсендә дә көннән - көн авырлаша бара. Шуңа күрә дә медиклар поликлиниканың беренче катында кечкенә генә кафе - кибет ачтылар. Хастаханәгә килүчеләргә кайнар сосискалар һәм пәрәмәчләр белән тамак ялгап алу мөмкинлеге туды. Әлеге ризыклар хастаханә кухнясында хәзерләнәчәк. Шунда ук бинаның уң канатында аптека пункты ачылачак.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

## ЭШЛӘРНЕҢ ИҢ АШЫГЫЧЛАРЫ КАЛДЫ

### "Уңыш -98" матбугат үзәге хәбәр итә

***Көннәр ничек кенә әйбәт торса да, шикәр чөгендере казу һәм туңга сөрү кебек эшләрне акрын алып барырга бернинди дә нигез юк. Икенчесенең соңгы бер көндә 1200 гектар чамасы гына мәйданда уздырылуы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Эш шул темп белән барганда, туңга сөрү октябрьгә дә калырга бик мөмкин әле. Дөрес, "Агрохимсервис", сөт - май комбинаты һәм РСУ ярдәмче хуҗалыкларында, "Дуслык"та, Синдряков исемендәге, "Сөлчә", "Төрнәс" хуҗалыкларында план үтәлеше 86 - 99 процент инде. Ә менә план 52 -57 процентка гына үтәлгән "Чирмешән" агрофирмасы, Хафизов исемендәге хуҗалыкларда бу эшнең көнлек темпы да ташка үлчим - 24-25 гектар гына. "Таң"да да сөрү агрегатлары тулы куәтенә эшли дип булмый әле.***

***Шикәр чөгендере кичәге көнгә 1700 гектар чамасы мәйданда казып алынды. Быел бу эшне "Игенче"дә аеруча тиз тоталар - анда татлы тамырның биштән өче казылды инде. "Өмет" агрофирмасында, "Киекле"дә дә эш ярыйсы бара. Ә менә "Алга", М.Җәлил исемендәге, Синдряков исемендәге, "Таң", Хафизов исемендәге, "Чулпан" һәм "Чирмешән" агрофирмасы хуҗалыкларында чөгендернең биштән бере дә казылмаган әле, көнлек эш темпы да әллә ни түгел.***

***Әзер чималны заводка озатуга килгәндә, соңгы бер көнне ташылганы мең тоннадан аз гына артыграк булып, барлык китерелгәне җиде мең ярым тоннадан күбрәк. Иң күп чөгендерне "Өмет" агрофирмасы, "Киекле" һәм "Рассвет" хуҗалыклары китерсә, "Татарстан" бу эшкә тотынды гына әле, Синдряков исемендәге, "Чирмешән" хуҗалыкларында да бик ашыкмыйлар.***

***Кукурузның силоска дигәненең 80 проценттан артыгы җыеп алынды инде. Әмма Синдряков исемендәге, "Өмет" агрофирмасы, "Татарстан" хуҗалыкларында ул ишле мәйданнарда тамырда әле.***

## СЕЛЕКТОР КИҢӘШМӘСЕ

Доллар котырынган, бәяләр көне - сәгате белән тирбәлеп торган заманда халыкның тормыш дәрәҗәсен ничек тә саклап калу мәсьәләсе ТР хөкүмәт башлыкларын нык борчый. 20 сентябрьдә ТР Премьер - Министры Рөстәм Миннеханов азык - төлек базары торышы, пенсияләр түләү, бәрәңге һәм яшелчә әзерләү, товар кредитын каплау мәсьәләләре буенча селектор киңәшмәсе үткәрде. Киңәшмәдә район хакимияте башлыгы, аның урынбасарлары, җитештерү, эшкәртү һәм сату оешмалары, контрольлек итү органнары җитәкчеләре катнаштылар.

***Яңалык адреслары буйлап***

## ҮЗЛӘРЕНӘ ДӘ, ХУҖАЛЫККА ДА

"Алга"га да ..., ниһаять, терлекчелектә реформалаштыруның җилләре килеп җитте. Май аеннан ана дуңгызлар караучы Юлия һәм Антонида Маркеловалар натуралата түләүгә күчү турында хуҗалык белән килешү төзегән иделәр. Беренче нәтиҗә үк бу ысулның һәр ике як өчен дә файдалы булачагын күрсәтте: терлекчеләр 43 баш анадан 371 баш үрчем алдылар. Шуның 258е хуҗалыкка тапшырылды. Үзләренең һәр икесенә 41әр баш дуңгыз баласы тиде. Әлбәттә, терлекчеләр бу кадәр үк малны үзләрендә калдырмадылар (әле бит дуңгызларның баш санын арттыру дигән сәясәт тә бар!), 30ар башны хуҗалыкка тапшырдылар.

Ике Маркелова да - күптәннән терлекчелектә эшләүче уңган, булдыклы хатыннар. Биредә чисталык, тәртип һәркем сокланырлык, малларның сакланышы да әйбәт. Гомумән, дуңгызчылыкта тулаем үзгәртеп кору башланды дияргә була. Ферма биналарында ремонт бара, яңа - чыгымнарга каршы технологияне кертергә дигән ният күздә тотыла. Эш шулай барса, уңай нәтиҗә озак көттермәс!

**С.НУРУЛЛИНА.**

## КИЗЛӘҮ СЕРЛӘРЕН АЧА

Менә ике атна инде районыбызның Кизләү - Киекле төбәгендә Казан археологлары эзләнү - казу эшләре алып баралар. Чирмешәннең Кизләү янындагы бер борылмасында сайлап алынган мәйданда имәнкискәлеләр культурасы чорына караган йорт урыны ачыкланган. Шунда ук табылган балчык чүлмәк кыйпылчыклары, күпсандагы сөякләр, ахак ташыннан ясалган муенсаның бер сәйләне (төймәсе), киемнең изүен эләктереп кую өчен хезмәт иткән зур бронза булавка, сөяктән ясалган ук очлыгы, авыл кешеләре көтү көткәндә табып китергән ташбалта һәм башка табылдыклар археологларның үзләрендә генә түгел, авыл халкында да зур кызыксыну уятты.

Экспедициячеләр төркеме бу юлы дүрт кешедән тора: безгә инде таныш булган фәнни хезмәткәрләр А.М.Гобәйдуллин һәм И.Р.Газыймҗановтан тыш "Иске Казан" тыюлыгының фәнни эзләнүләр буенча директор урынбасары, археолог Морат Мәҗит улы Кавиев һәм һәвәскәр археолог Радик Равил улы Вәлиуллин да килгән.

Кизләү янындагы мәйданда инде эш төгәлләнеп килә. Ә менә "Иске авыл" һәм "Курган" дип аталган ике урында егетләр баш күтәрми эшлиләр. Аларга Кизләү һәм Киекле мәктәпләренең югары класс укучылары да булышалар. Археологлар яныннан кеше өзелеп тормый: укытучылар, балалар һәм авыл халкы мондагы яңалыклар белән һәрдаим кызыксыналар. Җир астында калган серләргә беркем дә битараф түгел.

Археологларның эзләнү нәтиҗәләре турында тулырак мәгълүматны сезгә соңрак җиткербез.

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

## УРМАН ДЕПАРТАМЕНТЫНЫҢ 200 ЕЛЛЫГЫ БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛДЕ

Узган якшәмбедә урманчылар үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр. Быел ул Россиядә урман департаменты оештырылуга 200 ел тулган елда узуы белән дә истәлекле булды. Җомга көнне шул уңайдан Казанда үткән тантаналы җыелышка Нурлат урман хуҗалыгыннан да биш кеше чакырылган иде - җитәкчеләр белән бергә анда лесничийлар һәм мастер да барды. Шимбә көнне урманчылар һөнәри бәйрәмне үзләрендә билгеләп үттеләр. Анда коллективның иң алдынгы эшчәннәренә бүләкләр бирелде, рәхмәт белдерелде.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

# ӘЙДӘП БАРУЧЫ БУЛСЫН

**(“Татмясопром” холдинг компаниясе
“Нурлат” агрофирмасы баланс комиссиясе утырышыннан.)**

***УКУЧЫ ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ:***

***“Нурлат” агрофирмасы 1997 елның февраль аенда ит комбинаты, “Рассвет”, Синдряков исемендәге КХАлар һәм дуңгыз симертү буенча хуҗалыкара берләшмә базасында оештырылды. Аның максаты - җитештерү - эшкәртү - сату чылбырын эченә алган механизмны дөрес хәрәкәт иттереп, үз - үзен акларлык куәтле фирма төзү иде. Бу - районда гына түгел, республикада да шундый бердәнбер берләшмә саналды. Шуңа да аңа яшәешенең башлангыч чорында дотация дә бирелде, башка төр ярдәм дә күрсәтелде. Инде менә анда кертелгәннең ни рәвешле кире кайтуы турында сөйләшер чак җитте.***

***Баланс комиссиясе утырышын алып баручы “Татмясопром” холдинг компаниясе президенты Ә.Г.Булатовның сөйләшү өчен шактый кырыс тон сайларга мәҗбүр булуы аңлашыла иде. Агрофирма чыгымнарын акларлык хәлгә килсә генә бүгенге икътисадый шартларда яшәешен саклап кала алачак. Ә әлегә ул алдына куелган бу көн таләбен үтәргә тулысынча әзер түгел. Әхмәтҗан Галимҗанович бу фикергә дәлилләр китерде.***

Нигездә дуңгызчылыкны үстерү буенча махсуслашучы бу берләшмә әлеге тармакта иң стабиль күрсәткечләрне тәэмин итәргә, иң югары технологиягә таянып эшләргә, иң нәтиҗәле, югалтусыз юлларны эшкә җигәргә тиеш иде. Әмма, кызганычка каршы, моңа ирешелмәгән әле. Компания президенты җитештерү белән шөгыльләнүчеләрнең берсендә дә дуңгыз асрауның заманча технологиясе булмавын ачынып әйтте. Агрофирма буенча дуңгыз ите җитештерү 19 процентка кимегән. Дуңгыз итенең үзкыйммәте чиктән тыш югары, дебиторлык һәм кредиторлык бурычлары зур. Боларны иптәш Булатов иң әүвәл җитәкчеләрнең шәхси җаваплылыгы җитмәү белән аңлатты һәм ел ахырына кадәр хәлне төзәтү буенча программ чаралар, конкрет исәп - хисапны нәкъ алар авызыннан ишетергә теләгән иде. Әмма җитәкчеләрнең бу яктан әзерлеге йомшак булып чыкты. Әйтик, дуңгыз симертү буенча хуҗалыкара берләшмә директоры М.М.Сабитов ел ахырына дуңгызларның баш санын 8 меңгә җиткерергә җыенуларын белдерсә дә, моңа ничек ирешәселәрен ачык күзаллый алмый иде булса кирәк.Әлегә биредә бер ана дуңгыздан бары 3,4 бала алынган. Директор монда башкарылган эшләрне санаса да, продукциянең үзкыйммәтен арзанайту, үрчем алуны арттыру, ит җитештерүнең төгәл программасын бәян итә алмады. Утырышта хуҗалыкара берләшмәне киләчәктә баш предприятие буларак раслау һәм аның вазифаларын киңәйтү турында сүз урынлы күтәрелде. Әйтик, агрофирмага кергән хуҗалыкларда үрчем алу, малларны минераль витаминлы өстәмәләр белән тәэмин итү, комплексны маллар белән комплектлау кебек мәсьәләләрне ник ул үз өстенә алмаска тиеш?

Синдряков исемендәге КХА рәисе В.М.Әбдрәхимов адресына да урынлы тәнкыйть аз яңгырамады. Дөрес, ул ел ахырына 350 грамм тәүлеклек үсеш, 4 айда 1500 баш үрчем алырга да вәгъдә биреп өлгергән иде. Әмма ел башыннан читкә сатылган 2200 баш дуңгыз, 250 баш мөгезле эре терлекнең икътисадый исәп белән, файдага эшләнмәвен берничек инкарь итә алмыйсың. Бу - исәпләп эшләү үрнәге түгел.

Шундый ук тәнкыйть рассветлылар адресына да әйтелде: дуңгызларны һәм мөгезле эре терлекләрне түбән көрлектә сату, үзләрендә хуҗаларча анализ җитмәү һ.б.

Ә.Г.Булатов агрофирма эшчәнлегендә кичекмәстән җайга саласы бурычларга тукталды. Дуңгызларны асрау технологиясе үтәлми, төп көтүне көр, нәселле маллардан тупларга кирәк. Ел дәвамында 2,2 балалатуга һәр дуңгыздан кимендә 18 - 20 баш бала алырга, аларны имезүдән аерганда авырлыгын 18 - 20 килограммга, тәүлеклек артымны 360 - 380 граммга, ә симертүдә 500 граммга җиткерергә дигән бурыч куелды. Әхмәтҗан Галимҗанович беренче чираттагы эшләр рәтенә дуңгызларны ясалма орлыкландыру җайланмасы алу һәм бер ай эчендә орлыкландыру буенча белгеч әзерләүне дә атады. Әлбәттә, кышкылык азык туплау турында да җитди сүз булды, быелгы авыр елда үз заводларында сыйфатлы катнаш азык әзерләү, витаминлы үлән оны, катнаш силос, аксымлы группа азык булдыру бик мөһим. Һәм тагы бер зур сүз кадрларга кагылды. Җитәкченең ролен күтәрү, аны базар шартларында исәпләп, аз чыгымнар тотып нәтиҗәле эшләргә өйрәтү һәм шуңа башкаларны да туплау бик мөһим бүген. Кыскасы, агрофирма - республика өчен хуҗалык итү мәктәбе булып җитешергә, киләсе елдан җитештерүне арттыру һәм нәтиҗәлелеген күтәрү исәбенә чыгымнарын акларлык яшәүгә күчәргә тиеш.

Утырышта “Нурлат” агрофирмасы генераль директоры Р.С.Чахмахчев һәм район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев чыгыш ясадылар. Юрий Владимирович районда дуңгызчылыкны үстерү юлында “Нурлат” агрофирмасының әйдәп баручы ролен үтәмәвен белдерергә мәҗбүр булды, агрофирманың зооветхезмәткәрләре эшенә дә канәгатьсезлек белдерде. Шартлар тудырылып та күрсәткечләр тәэмин итә алмаган агрофирмага үрнәк алыр өчен мисал итеп Муса Җәлил исемендәге КХА дуңгызчылыгын китерде. Биредә бер балалатуда 8,8әр баш үрчем алына, тармакның рентабельлелеге 50 процентка җиткән!

Сөйләшү шулай конкрет бурычлар куеп тәмамланды. Алар үтәлгәндә генә агрофирма үзенең төп билгеләнешенә җавап бирәчәк, базар икътисады шартларында тотрыклы яшәешкә ирешәчәк - катнашучылар моны тирәнтен аңлап таралыштылар дип уйлыйбыз.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

### Сатып алучы колагына

# СЕЗОНЛЫ ГАРАНТИЯ СРОКЛАРЫ

***Сез бер пар аяк киеме сатып алдыгыз ди - ә ул сезгә ярамады. Күпмедер вакыттан соң кабат кибеткә тапшырырга уйласагыз да, сезон узуны сылтау итеп, аны сездән кабул итмәделәр. Бу очракта сатып алучы ни эшли ала? Әлеге сорауга сатып алучы хокукларын яклау буенча район комитеты рәисе Р.СУФИЯНОВ җавап бирә:***

- Мондый мөрәҗәгать итүләр еш очрый. ТРның “Сатып алучылар хокукларын яклау турында”гы Законының 21нче маддәсендә әйтелүенчә, товарның гарантия срогы кулланучының сатып алу көненнән башлап исәпләнә. Әгәр сатылган көнен билгеләп булмаса, бу срок товарның җитештерелү көненнән исәпләнә. Гарантия срогы билгеләнмәгән товарларга мөнәсәбәттә кулланучы товарның җитешсезлеген 6 ай эчендә күргән булса, үзенең таләпләрен куя ала. Сезонлы товарлар өчен бу сроклар әлеге сезон башланган моменттан исәпләнә. Ә бу срок ТР Министрлар Кабинеты тарафыннан сатып алучының нинди климатик шартларда яшәвеннән чыгып билгеләнә. ТР Министрлар Кабинетының 1998 елгы 5 сентябрь карары ( 611 - р номерлы) белән сезонлы билгеләнештәге товарлар өчен түбәндәге сезонлы гарантия сроклары билгеләнде:

***кышкы - 16 ноябрьдән 15 марткача,***
***язгы - 16 марттан 15 майгача,***
***җәйге - 16 майдан 31 августкача,***
***көзге - 1 сентябрьдән 15 ноябрьгәчә.***

Бу нәрсә аңлата соң?

Мәсәлән, әгәр сез җәй көне тун сатып алып, кышкы сезон җиткәч, аны кия башлагансыз һәм шул вакытта җитешсезлеген тапкансыз икән, үзегезнең канәгатьсезлегегезне сатучыга (җитештерүчегә) шушы сезонда белдерә аласыз. Бу очракта товар чегының сакланган булуы шарт. Ләкин тагын бер нәрсәне истә тотыгыз. Әгәр товарны базардан алсагыз, кагыйдә буларак, чек бирмиләр, һәм сатып алучының таләпләре ирекле рәвештә һәрвакытта да канәгатьләндерелми. Шуңа күрә, зур яки кыйммәтле әйберләр сатып алганда шаһитләр булдыру шарт. Әгәр бу эш хөкем дәрәҗәсенә җитсә, алар сезнең сатып алу фактыгызны раслый алачаклар. Сәүдә предприятиеләре һәм шәхси предприятиеләрнең сәүдә залларында сезонлылык сроклары турында мәгълүмат булырга тиеш.



***Шамил Касыйм улы Бикиев - Яңа Иглайда танылган шофер. Ике дистә елдан артык үз һөнәренә тугрылыклы булып калган тәҗрибәле шофер өчен ГАЗ - 53 аның аерылгысыз дусты да, гомерлек юлдашы да. Чәчү вакытында кырга орлык чыгару, яңа уңышны ындыр табагына ташу, хуҗалыктагы тагы дистәләгән төрдәге эшләрне башкару аңа тапшырылган.***

***Уҗым культураларын үзвакытында чәчеп өлгерү өчен зур тырышлыгын куйды ул - кырга орлыкны чыгарып торды. Хәзер ул чөгендер ташу белән мәшгуль. Фотохәбәрчебез Н.Азизов “Рассвет” КХАсы шоферы Ш.Бикиевны элеваторга беренче ашлыкны китергәч төшереп алган.***

### ТУ - 324 ПРОЕКТЫ ХАЛЫКАРА МӘЙДАНГА ЧЫГА

***10 сентябрьдә Лондонда Казан авиация производство берләшмәсендә Ту - 324 самолеты булдыруга кагылышлы килешүгә кул куелды. Сүз Казан авиация производство берләшмәсенең булачак самолеты өчен көч җайланмасының мониторинг (контроль) системасын эшләү һәм Казанга тапшыру турында бара. Документка Татарстан Премьер - министры киңәшчесе Назир Киреев (самолет төзүгә идарә итү хөкүмәт төркеме исеменнән), Туполев исемендәге АНТК генераль директоры Василий Александров, икенче яктан - “Вибро Мэтр” җитәкчесе Ричард Гривс кул куйды.***

***Лондоннан телефон буенча Н.Киреев хәбәр иткәнчә, бу килешүгә кул кую проектны тормышка ашыруда алга таба ныклы адым булып тора. Хикмәт шунда ки, төрле чит ил компанияләре белән тагын 11 контракт төзергә кирәк булачак.***

***(“Ватаным Татарстан”нан.)***

## ДӨНЬЯ АВАЗЫ

**”О**лы җиделек”нең атна ахырында Лондонда узачак утырышына Россиягә рәсми чакыру җибәрелмәгән. Рейтер агентлыгы хәбәренә караганда, әлеге утырыш Бөекбритания тәкъдиме буенча үткәрелә һәм анда Россиядәге икътисади хәл тикшереләчәк.

* **Ә**рмәнстанның Армавир районындагы Зартонк авылында ваба авыруы таралган. Инде ике кеше шул авырудан вафат булган, 200е хастаханәгә салынган. Сәламәтлек саклау министры сүзләренә караганда, әлеге авыруның таралуына һаваның бик кызу торуы сәбәп булган.

* **Б**еларусь товарларының Россия һәм Украинага чыгуын кисәтү өчен, чик буйларында яңа даими постлар төзелгән һәм анда милициянең өстәмә көчләре җибәрелгән. Президент Лукашенконың күрсәтмәсе нигезендә тоткарланган контрабанда товарлары гына түгел, аны ташуда катнашкан транспорт чаралары да конфискацияләнәчәк.

***И**станбул шәһәрендә полиция 4,5 килограмм авырлыктагы, составында уран булган радиоактив матдәне сатарга маташкан контрабандистларны кулга алган. Тикшерүләр атом - төш коралының бер компоненты булган әлеге материалның Россиядән кертелгән булуын күрсәтә.

* **С**оңгы вакытта Приморьеда кытайлылар тарафыннан Россия - Кытай чиген бозу очраклары ешайган. Сентябрь башыннан гына да 52 кытайлыны үз иленә кире озатканнар. Россия Федерациясенең чик буе федераль хезмәте вәкиле фикеренчә, мондый хәлнең сәбәбен илдә икътисади хәлнең катлаулануы нәтиҗәсендә контрольнең дә йомшавыннан эзләргә кирәк.

* **Т**өньяк Корея белән АКШ арасында ракета кораллары технологиясен таратмау мәсьәләсе буенча сөйләшүләрне яңадан торгызу турында килешүгә ирешкәннәр. Моңа Американың Пхеньянга 200 мең тонна азык - төлек бүләк итәргә вәгъдә бирүе булышлык иткән.

**(“Шәһри Казан”нан.)**

